**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 380

г. Казань

Нурлат муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Кара Алтын предприятиесе» ЯАҖнең Нурлат муниципаль районында урнашкан, «Кара Алтын предприятиесе» ЯАҖ милкендә булган 5,6 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:32:020202:194 кадастр саны белән кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков